Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Исәнбай авыл җирлегенең Исәнбай торак пунктында **ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

2019 ел, 17 октябрь № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруныц гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Исәнбай авыл җирлеге Исәнбай торак пунктында гражданнар җыены **КАРАР БИРДЕ:**

1. I группа инвалидлар, ялгыз яшәүче өлкән кешеләрдән (80 яшькә җиткән), торып укучы студентлардан, иректән мәхрүм ителгән физик затлардан тыш, Исәнбай авыл җирлеге Исәнбай авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 2020 елда үзара салым акчаларын 500 сум күләмендә кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирлектә әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:
   - Исәнбай авыл җирлеге территориясендәге суүткәргеч челтәре өчен су насослары, колонкалар, ремонт очен сантехник материаллар, суүткәргечләрне алмаштыру өчен полиэтилин торбалар һәм краннар сатып алу;
   - Исәнбай авыл җирлеге территориясендәге урам утларының төзеклеге очен материаллар, алмаштыру өчен лампалар, дроссельләр һәм фонарьлар сатып алу;
   - Авыл территориясенә кергән юлларны кардан чистарту;
   - Исәнбай авыл җирлеге өчен МТЗ-82 тракторы сатып алу.

3.Гражданнарның җыен нәтиҗәләрен Исәнбай авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштыру, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм http://agryz.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районы сайтында бастыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү очен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе Ф.Ф. СИРАЕВ

Совет Исенбаевского сельского поселения
Исәнбай авыл җирлеге Советы